**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Иске Казиле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

05 сентябрь 2023 ел № 80

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 29 апрелендәге 92/1 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясенен 29.12.2022 ел № 612-ФЗ «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацын һәм «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм «конкуренцияне яклау турында»Федераль законның 18_1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында " 2022 елның 19 декабрендәге 541-ФЗ номерлы Федераль законның үз көчен югалтуын тану хакындагы карарлар нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге Советының 2014 елның 29 апрелендэге 92\1 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 27 статьясының 5 өлеше 5 пункты түбәндәге эчтәлектәге 5.1 пункт белән тулыландырырга:

«5.1. «әгәр мондый килешү РФ Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 маддәсендә каралган булса, капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше кыяфәтен килештерү.»;

1.2. 28 статьяның 7 пунктында «башкарма документацияне алып бару составы һәм тәртибе» дигән сүзләрне алып ташларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Кама Тамагы муниципаль районы,
Иске Казиле авыл җирлеге башлыгы
Кама Тамагы муниципаль районы,
Иске Казиле авыл Советы Рәисе И.Х. Сагьдиев